КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 август г.Казань № 549

2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру белән бәйле хезмәтләр күрсәтүгә юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (алга таба – Субсидия бирү тәртибе);

2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе (алга таба – Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе).

3. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә:

Татарстан Республикасының социаль яклау, халыкны эш белән тәэмин итү, балалар һәм яшьләр эшләре буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе гамәле туктатып торыла;

Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренең пенсионер булган хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү әлеге карар белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе нигезендә яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе нигезендә, аларның үзләре сайлап алуы буенча гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру мониторингын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

әлеге карар белән расланган Субсидия бирү тәртибеннән һәм Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибеннән файдалану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков